**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 7 августындагы 3266 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2020 елның 10 июнендәге 1660 номерлы**
**«Несмелов урамындагы (Несмелов урамыннан**
**Набережная урамына кадәр) җир кишәрлекләре өлешләренә**
**ачык сервитут билгеләү турында»гы карарын**
**гамәлдән чыккан дип тану турында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 48 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанда юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү буенча баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең 2024 елның 24 маендагы 8836/КЗИО-ВХ номерлы гаризасын исәпкә алып **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 10 июнендәге 1660 номерлы «Несмелов урамындагы (Несмелов урамыннан Набережная урамына кадәр) җир кишәрлекләре өлешләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар** **А.Р.Нигъмәтҗанов**